КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 декабрь г.Казань № 1172

2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген расларга.

2. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 31 гыйнвар, 49 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы

инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 19 июнь, 440 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 9 сентябрь, 746 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 18 декабрь, 1637 нче карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 5 декабрь, 1101 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 4 март , 118 нче карары белән расланды

2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 - 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге

I. Өстенлекле инвестиция проектлары:

1. Авыл хуҗалыгы һәм балык үрчетү:

1) «3 550 сыерга исәпләнгән «Наратлы» эре мөгезле терлекләр терлекчелек комплексын һәм 5 100 башка исәпләнгән сөт токымындагы эре мөгезле яшь терлекләр үстерү өчен мәйданчыклар төзү» («Северная Нива Татарстан» ҖЧҖ, Бөгелмә муниципаль районы);

2) «Татарстан Республикасы Кукмара районы Тырыш авылы янында урнашкан савым сыерлары өчен 1 006 исәпләнгән сөт товарлары фермасы» («Вахитов» ҖЧҖ, Кукмара муниципаль районы);

3) «Тукай муниципаль районының Комсомол авыл җирлегендә 4 550 башка исәпләнгән дуңгызчылык комплексын реконструкцияләү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Тукай муниципаль районы);

4) «Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегендә 6 400 башка исәпләнгән эре мөгезле яшь терлекләр үстерү һәм симертү буенча махсуслаштырылган ферма төзү» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

5) «Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлегендә 300 баш үгезгә ясалма орлыкландыру станциясе төзелеше» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

6) «Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегендә 3 000 фураж баш эре мөгезле терлеккә исәпләнгән сөт товары комплексы төзелеше» («Камский бекон» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

7) «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Степановка авылында 2.400 башка исәпләнгән сөт товары фермасы төзү (1 нче чират - 1 200 башка)» («Август-Минзәлә» ҖЧҖ, Минзәлә муниципаль районы);

8) «Чаллы элеваторы» АҖнең элеватор куәтләрен реконструкцияләү - 42 000 тоннага ашлык саклау куәтләрен төзү» («Чаллы элеваторы» АҖ, Чаллы шәһәре);

9) »Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында 4 000 башка исәпләнгән сөт юнәлешендәге терлекчелек комплексы төзелеше» («Сарман» агрофирмасы” ҖЧҖ, Сарман муниципаль районы);

2) «Үсемлекләр полимерлары җитештерү буенча биозавод төзелеше» («Пектин» ҖЧҖ, Чүпрәле муниципаль районы);

11) «Татарстан Республикасы Кайбыч районы Ульянково авылы янындагы 3 400 сыерга сөт товары фермасы төзелеше» («Август-Кайбыч» ҖЧҖ, Кайбыч муниципаль районы);

12) «Бөгелмә муниципаль районында бер мәртәбә саклау күләме 120 мең

тоннага кадәр булган бөртекле һәм майлы культураларны саклау өчен элеватор төзелеше» («Август-Лениногорск» ҖЧҖ, Бөгелмә шәһәре);

13) «Яшелчә, җиләк-җимеш һәм җиләкләр саклау, өстәмә эшкәртү, сату алдыннан әзерләү, шок туңдыруы һәм сату буенча комплексly предприятие булдыру» («ТАКПО» ҖЧҖ, Әлмәт шәһәре);

14) «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында саклау күләме 30 000 тоннага кадәр элеватор төзү» («БИО-АГРО» ҖЧҖ, Чирмешән муниципаль районы);

15) «Лубян культураларны беренчел эшкәртү» («ТН-Биотехнологик парк» ҖЧҖ, Азнакай муниципаль районы);

16) «Ашлыкны тирәнтен эшкәртү күләме елына 250 мең тонна (I этап)» («Биотех-агро» ҖЧҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

17) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Шуран авылында 6 000 тоннага исәпләнгән яшелчәсаклагыч төзелеше» (Лаеш муниципаль районы «Шураны Эко гарден» авыл хуҗалыгы эшкәртү-сату кооперативы, Лаеш муниципаль районы);

18) «Груссманнов» сөт-генетик комплексы» («Закрома» ҖЧҖ, Яңа Чишмә муниципаль районы).

2. Азык-төлек продуктлары җитештерү:

1) «Казан сөт комбинатында җитештерүне модернизацияләү, киңәйтү» («Казан сөт комбинаты» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

2) «Туңдырма һәм кондитер әйберләре җитештерү фабрикасы төзелеше» («Славица» туңдырма фабрикасы» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

«4) «Сыр ясау сөт комбинаты төзелеше» («Кукмара сөт комбинаты» ҖЧҖ, Кукмара муниципаль районы).»;

4) «Гомуми куәте 6 000 тонна булган солодовня төзелеше» («Таткрахмалпатока» АҖ, Югары Ослан муниципаль районы).

3. Химик җитештерү:

1) «Этилен буенча елга 600 мең тонна куәтле олефиннар җитештерү буенча яңа комплекс төзелеше» («Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре);

2) «Суда эри торган пленкалар җитештерүне оештыру» («Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

3) »Нәфис Косметикс» АҖндә көнкүреш химиясе һәм техник продукция җитештерүне киңәйтү һәм техник яктан яңарту» («Нәфис Косметикс» АҖ, Казан шәһәре);

4) «Сыгылмалы композит торбалар (СКТ) җитештерү» («Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ, Алабуга муниципаль районы);

5) «Электролиз хлорыннан тоз кислотасы җитештерү» («Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АҖ, Менделеевск шәһәре);

6) «Түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү заводының «В» реакторын реконструкцияләү» («Казаноргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре);

7) «50 мең тонна куәтле гексен-1 сәнәгать җайланмасы төзелеше» («Казаноргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре);

8) «Метионин җитештерү» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы).

4. Башка металл булмаган минераль продуктлар җитештерү:

1) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында цемент терминалы төзелеше» («Ресурс-М» ҖЧҖ, Тукай муниципаль районы);

2) «Проппант җитештерү заводы» («Шешмаойл» АҖ, Алабуга шәһәре).

5. Металлургия производствосы һәм әзер металл эшләнмәләр җитештерү:

«Газ турбиналы двигательләр (ГТД) детальләрен кою производствосын оештыру» («КЭР-Холдинг» ИК» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

6. Машиналар һәм җиһазлар җитештерү:

1) «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә сыекландырылган табигый газ (СТГ) эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» («Казанкомпрессормаш» АҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

2) «Сәнәгатьнең төрле тармакларының технологик процессларын автоматлаштыру системалары өчен билгеләнгән микропроцессор электроника базасында «АБАК» программалаштырыла торган логик контроллерларның югары технологияле җиһазларын җитештерүне киңәйтү» (НИЦ «Инкомсистемалар» АҖ, Казан шәһәре);

3) «ГТ-006 газ турбинасын җитештерү һәм энергия-газ-нефть химиясе җиһазларына запас өлешләр әзерләү» («Камэнергомаш» ҖЧҖ, Түбән Кама шәһәре);

4) «Россия Федерациясендә бетон буенча бораулар, керамика һәм пыяла буенча бораулар, герметик өчен пистолетлар һәм канцелярия пычаклары өчен лезвиялар җитештерү буенча бердәнбер завод төзү проекты» («ТПК Идел буе инструменты» ҖЧҖ, Питрәч муниципаль районы).

7. Транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү:

1) «Елына 36 самолетокомплект күләмендә МС-21 самолетының полимер-композицион детальләр һәм канат җыю берәмлекләре, механизация һәм койрык ныгыту агрегатларын әзерләү» (Казан шәһәрендә «АэроКомпозит» АҖ филиалы, Казан шәһәре);

2) «Казан вертолет заводының динамик сынаулар корпусын (ДСК) җиһазлау. Детальләр һәм җыю берәмлекләре, төеннәр һәм агрегатлар өчен стендлар эшләү һәм аларны китерү» («Казан вертолет заводы» АҖ, Казан шәһәре);

3) «Казан вертолет заводы» АҖндә вертолетлар җитештерүне киңәйтү һәм технологик модернизацияләү» («Казан вертолет заводы» АҖ, Казан шәһәре).

8. Электр энергиясе, җылылык, газ һәм су җитештерү һәм бүлү:

1) «Чаллы ТЭЦында 236 МВт куәтле пар-газ җайланмасын (ПГҖ) төзү» («Татэнерго» АҖ, Чаллы шәһәре);

2) «Бастыруга каршы турбина күчерү, пар көч циклын кулланып эшләүче 40 МВт куәтле ТГ-3 станциясе номеры, пар газы генерирлаучы объектны кулланып, газ турбинасы эшли торган эшкә, 155 МВт казан-утилизаторы белән билгеләнгән ГТУ-1 станция номеры» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

3) «Б.Крыловка һәм Краснококшайская урамнары киселешендә ТК11-5/10 дән алып УТ-4 кә кадәр участокта 11 номерлы магистраль җылылык үткәргеч төзелеше» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре);

4) »КТЭЦ-1дән «Горки» котельныена кадәр 5 нче магистраль җылылык

үткәргеч төзелеше» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре);

5) »Зеленодольск шәһәрендә энергоүзәк төзелеше» («КЭР-Генерация» ҖЧҖ, Зеленодольск шәһәре);

6) «Җылылык энергиясен кулланучыларны исәпкә алу җиһазлары белән элемтә оештыру» («Татэнерго» АҖ, Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Түбән Кама, Зәй муниципаль районнары);

7) «Т-100/120-130-2 пар турбинасы 5 номерлы генератор белән. Турбиналарны, югары басым цилиндрын алмаштырып, техник яктан яңадан коралландыру» («ТГК-16» АҖ, Түбән Кама шәһәре);

8) «ПТ-60-130/13 пар турбинасы 2 номерлы генераторы белән. Турбиналарны, югары басымлы цилиндрны һәм 30 ат сайлап алуны оештыру белән регенератив җылыткычларны алыштыру белән, техник яктан яңадан коралландыру» («ТГК-16» АҖ, Түбән Кама шәһәре);

9) «Казаноргсинтез» ГАҖ өчен 250 МВт куәтле пар-газ җайланмасы (ПГҖ) төзелеше» («Казаноргсинтез» ГАҖ, Казан шәһәре).

9. Транспорт һәм элемтә:

1) «Яшел автобус һәм йөк автомобильләре» («РариТЭК автомобиль заводы» ҖЧҖ, Тукай муниципаль районы);

2) «КАМАЗ автомобильләренең модель рәтен үстерү һәм аның производствосы өчен җитештерү куәтләрен модернизацияләү» («КАМАЗ» ГАҖ, Чаллы шәһәре);

3) «Алексеевск муниципаль районында йөк елга порты төзелеше» («Автострада» АҖ, Алексеевск муниципаль районы);

4) «Шәле (М-7) - Баулы (М-5)» түләүле автомагистрале төзелеше кысаларында Татарстан Республикасында «Казан - Оренбург» федераль автомобиль юлының яңа маршрутын үстерү өчен «Әлмәт-Баулы» автомобиль юлы төзелеше» («Автострада» АҖ, Әлмәт, Баулы муниципаль районнары);

5) «Шәле (М-7) - Баулы (М-5)» автомагистрале төзелеше кысаларында Татарстан Республикасында «Казан - Оренбург» федераль автомобиль юлының яңа маршрутын үстерү өчен «Баулы (М-5) – Шалты» автомобиль юлы төзелеше» («Автострада» АҖ, Баулы муниципаль районы);

6) «Шәле (М-7) - Баулы (М-5)» түләүле автомагистрале төзелеше кысаларында Татарстан Республикасында «Казан - Оренбург» федераль автомобиль юлының яңа маршрутын үстерү өчен «Шәле (М-7) – Наратлык» автомобиль юлы төзелеше» («Автострада» АҖ, Питрәч, Арча, Биектау, Әтнә муниципаль районнары);

7) «Вознесенский тракты. Казан шәһәренең Совет районында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Җиңү проспектыннан алып «Идел» М-7 автомобиль юлына кадәр түләүле участок төзелеше» («Оптима-технология» ҖЧҖ, Казан шәһәре, Питрәч муниципаль районы);

8) «Лаеш төене» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Лаеш муниципаль районы);

9) «Казан шәһәре Киров районындагы Несмелов урамыннан «Серебряный бор» торак комплексы аша «Идел» М-7 федераль әһәмияттәге автомобиль юлына кадәр автомобиль юлын төзү. II этап - «Серебряный бор» торак комплексыннан федераль әһәмияттәге «Идел» М-7 юлына кадәр участок» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре);

10) «Дербышка дублеры очу трассасы» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре);

11) «Оренбург тракты дублеры» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре).

10. Башка проектлар:

1) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын перспективалы үстерү, шул исәптән III чират төзелеше» («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» АҖ, Алабуга муниципаль районы);

2) «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасын перспективалы үстерү» (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» АҖ, Казан шәһәре, Югары Ослан, Лаеш муниципаль районнары);

3) «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә «Яшел Үзән» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона булдыру» (В.Д.Шашин ис. «Татнефть» ГАҖ, Зәй муниципаль районы);

4) «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Яшел Үзән-2» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын булдыру» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

5) «Яңа җир» иммерсив паркы» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Бөгелмә муниципаль районы);

6) «Казан вертолет заводы» АҖ җитештерү белем бирү үзәге белән механик эшкәртү буенча махсуслашу үзәге төзелеше» («Казан вертолет заводы» АҖ, Казан шәһәре);

7) «Перинаталь үзәк» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Әлмәт муниципаль районы);

8) «Әлмәт шәһәрендә концерт залы» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Әлмәт муниципаль районы);

9) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә логистик технопарк, 6:24:000000:3507 җир кишәрлегендә 1 номерлы корпус» («ИнПарк-Казан» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

10) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә логистик технопарк, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә 2 номерлы корпус» («ИнПарк-Казан» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

11) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә логистик технопарк, 16:24:150301:1937 җир кишәрлегендә 5 номерлы корпус» («ИнПарк-Казан» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

12) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында «Нәфис Косметикс» АҖ склад комплексы төзелеше» («Нәфис Косметикс» АҖ, Зеленодольск муниципаль районы) ;

39) «Казан марина» туристлык территориясен төзү» («Туризм.РФ Татарстан Республикасы» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

14) «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Северные ворота» индустриаль (сәнәгать) паркын төзү («Казаноргсинтез» ГАҖ, «Северные

ворота» АЖ, Казан шәһәре);

15) «Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк булдыру («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ), 4 этап («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

16) «Дружба» индустриаль-логистика паркы – I чират» («ИЛП «ПОТОК» СЗ ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

17) «Химград» технополисының җитештерү инфраструктурасын киңәйтү» («Химград» АЖ, Казан шәһәре);

18) «Мегастрой» күпләп сату комплексы» («Татьяна» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

19) «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә «Эссен» тулай торак белән» җитештерү-склад комплексы төзелеше» («Эссен Продакшн АГ» АЖ, Тукай муниципаль районы);

20) югарыда күрсәтелмәгән, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары нигезендә булдырылган, технопарклар, индустриаль, сәнәгать парклары, инновацион фәнни-технологик үзәкләр территорияләрдә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

21) югарыда күрсәтелмәгән, Татарстан Республикасының монопрофильле торак пунктларын үстерүнең комплекслы инвестицияләү планнарына кергән инвестиция проектлары;

22) югарыда күрсәтелмәгән, үсеше алга киткән территорияләрдә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

23) сатулар үткәрмичә генә арендага җир кишәрлекләре биреп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган масштаблы инвестиция проектлары;

24) капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләр төзеп гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

25) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын гамәлгә ашыру максатларында бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы бурычларын түләү күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган инвестиция проектлары Татарстан Республикасының инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелергә тиеш;

26) югарыда күрсәтелмәгән, дәүләти-хосусый партнерлык һәм концессия килешүләре төзү белән гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

27) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы һәм «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

28) Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәге территориясендә гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлары;

29) Төбәк квалификация комиссиясе беркетмәләре, индивидуаль үсеш карталары нигезендә сайлап алынган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларында катнашучылар тарафыннан югарыда күрсәтелмәгән, гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары.

II. Салым ташламалары рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү белән гамәлгә

ашырылуга хупланган өстенлекле инвестиция проектлары:

1. Авыл хуҗалыгы:

2) «Биосфера-Фиш» балык үрчетү комплексы (3 нче чират)» («Биосфера-Фиш» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).

2. Электр энергиясе, җылылык, газ һәм су җитештерү һәм бүлү:

1) «Елына 550 000 тонна каты коммуналь калдыкларны термик зарарсызландыру заводы төзелеше, аннан соң электр энергиясен эшләп чыгару белән» («Альтернатив генерирующая компания-2» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

2) «Түбәнкама нефтехим» ГАҖ пар-газ җайланмасы - җылылык электр станциясен (ПГҖ-ҖЭС) төзелеше» («Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре).

3. Башка проектлар:

«Kazan Palace by Tasigo (2 нче чират)» («Полистрой Иншаат Тааххют Санайи Ве Тиджарет Аноним Ширкети» АҖ, Казан шәһәре).